**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының**
**Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында**
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**24 ноябрь, 2020 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәгатьтә, 23 ноябрендә 14 сәгатьтә, 24 ноябрендә 11 сәгатьтә һәм 18 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Ульянково авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- кирәкле материаллар сатып алып, күперләрне ремонтлау.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 340 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -182, бу 54% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 177 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 5 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Ульянково авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- кирәкле материаллар сатып алып, күперләрне ремонтлау.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә» - кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ульянково авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Сундурова